**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№492**
**23.01.2026**

Яр Чаллы шәһәренең «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗат сарае» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗат сарае» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗат сарае» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2021 елның 12 мартындагы 1714 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 23 гыйнварындагы
492 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
«1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗат сарае» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе, сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Укучылар өчен интеллектуаль уен үткәрү | сум/кеше | 82,60 |
| 2. | Укучылар өчен интеллектуаль уен үткәрү (урынга барып) | сум/кеше | 126,88 |
| 3. | Укучылар өчен спорт уены үткәрү | сум/кеше | 81,87 |
| 4. | Укучылар өчен спорт уены үткәрү (урынга барып) | сум/кеше | 126,45 |
| 5. | «Яр буе» паркы территориясендә спорт-сәламәтләндерү чарасы | сум/кеше | 163,79 |
| 6. | Укучылар төркеме өчен театр чарасы үткәрү | сум/кеше | 910,19 |
| 7. | Массакүләм театр тамашасы | сум/кеше | 808,86 |
| 8. | Кинотеатрда киносеанс | сум/кеше | 84,14 |
| 9. | Этнографик музейга экскурсия | сум/кеше | 84,03 |
| 10. | Укучылар төркеме өчен интерактив викторина | сум/кеше | 88,63 |
| 11. | Укучылар төркеме өчен күңел ачу-танып белү программасы (мастер-класс) | сум/кеше | 70,90 |
| 12. | Укучылар төркеме өчен инглиз телендә театр тамашасы | сум/кеше | 172,39 |
| 13. | Театр залында чара оештыру һәм үткәрү | сум/сәгать | 4525,36 |
| 14. | Концерт залында чара оештыру һәм үткәрү | сум/сәгать | 5532,30 |
| 15. | Өстәл теннисын прокатка бирү (1 өстәл) | сум/сәгать | 320,62 |
| 16. | Костюмнарны прокатка бирү (1 костюм) | сум/тәүлек | 620,75 |
| 17. | Укучыларның кече төркемнәре өчен театр-уен тамашасы | сум/кеше | 304,02 |
| 18. | «Гном» кинотеатрында чара оештыру һәм үткәрү | сум/сәгать | 2544,77 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 19. | Театр залы фойесында чара оештыру һәм үткәрү | сум/сәгать | 2033,42 |
| 20. | Бәйрәм чаралары залында чара оештыру һәм үткәрү | сум/сәгать | 2046,63 |
| 21. | «Гном» кинотеатры холлында чара оештыру һәм үткәрү | сум/сәгать | 1508,34 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева